КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 2 сентябрь г.Казань № 715

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү турында» 2023 ел, 11 март, 231 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү турында» 2023 ел, 11 март, 231 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 8 февраль, 69 нчы; 2024 ел, 16 июль, 566 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның унынчы абзацында «Алга» һәм «Тимер» батальоннарында» сүзләрен «Алга», «Тимер» һәм «Батыр» батальоннарында» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Йорт биләмәсе участогы чикләре эчендә газ үткәрүгә һәм йорт эчендәге газ җиһазын сатып алуга бәйле чыгымнарны каплауга субсидия бирү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

2.1 пунктның тугызынчы абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Үзәк бүлеге ведомствоара рәсми сораулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасыннан файдаланып, электрон рәвештә субсидия бирү өчен кирәкле түбәндәге мәгълүматны ала:

яшәү урыны буенча теркәлү турында;

инвалидлык һәм аның төркеме булу турында (булганда);

бала тууны дәүләт теркәвенә алу турында;

никахлашуны (аерылышуны) дәүләт теркәвенә алу турында;

үлемне дәүләт теркәвенә алу турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында хокукы теркәлгән торак урынга милек хокукы турында;

балага опека билгеләү турында;

ата-ана хокукларыннан мәхрүм итү (чикләү, торгызу) турында; ата-ана хокукларын чикләүне гамәлдән чыгару турында белешмә, баланың гомеренә яки сәламәтлегенә турыдан-туры куркыныч янаганда аны тартып алу турында белешмә;

хезмәт бурычларын яки башка бурычларны үтәгән өчен акчалата бүләкләү (стимул бирү характерындагы түләүләрне кертеп), башкарылган эш, күрсәтелгән хезмәт, гражданлык-хокукый шартнамә кысаларында гамәлләр кылу өчен акчалата бүләкләү турында;

Россия Федерациясе законнары һәм (яки) Россия Федерациясе субъекты законнары нигезендә алынган пенсия, пособиеләр һәм башка шундый түләүләр, шул исәптән мәҗбүри социаль иминият түләүләре һәм компенсация характерындагы түләүләр суммалары турында;

керемнәр исәпкә алына торган исәп-хисап чорында эшкә сәләтсез затларны карауны гамәлгә ашыру турында;

инвалид баланы карауны гамәлгә ашыру турында;

гариза бирүченең яки аның гаилә әгъзаларының Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе, Херсон өлкәсе һәм Украина территорияләрендә үткәрелә торган махсус хәрби операциядә катнашуы турында.

Гариза бирүчеләр яки алар ышанычнамә нигезендә вәкаләт биргән затлар әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәгә ия документларны үз инициативасы белән Үзәк бүлегенә тапшырырга хокуклы.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин